| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.09.2020 № 776

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 октябрендәге 946 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Нурлат шәһәр прокурорының 21.09.2020 ел, № 02-08-01-20/89 протесты, «Һәвәскәр балыкчылык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2018 ел, № 475-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 05.10.2017 ел, № 946 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Әлеге Кагыйдәләр Нурлат муниципаль районы территориясендә теләсә нинди милек рәвешендәге халык һәм оешмалар өчен суны куллануга (файдалануга) карата, кешеләр коена торган, ял итүгә, туризм, спортка, һәвәскәр балыкчылык, су эчерүгә карата куела торган таләпләрне билгели.»;

1.3 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

һәвәскәр балыкчылык - шәхси куллану һәм рекреация максатларында су биоресурсларын файдалану (тоту) буенча эшчәнлек алып бару;»;

1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Һәр граждан гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосасыннан, алар янында йөрү һәм булу өчен, шул исәптән һәвәскәр балыкчылыкны гамәлгә ашыру һәм йөзү чаралары белән килеп туктау өчен, файдаланырга (механик транспорт чараларыннан башка) хокуклы.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Нурлат муниципаль районының гомуми файдаланудагы су объектларында Һәвәскәр балыкчылык 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында Федераль закон, «Һәвәскәр балыкчылык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2018 ел, № 475-ФЗ Федераль закон нигезендә тормышка ашырыла».».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А.Газизуллин